ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.05.2022 г. Заинск № 227

**«Ташламалы транспорт картасы һәм балалар өчен ташламалы транспорт картасы буенча транспорт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле рәвештә транспорт оешмаларына Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 12 ноябрендәге 672 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында" 2021 елның 29 ноябрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Ташламалы транспорт картасы һәм балалар өчен ташламалы транспорт картасы буенча транспорт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле рәвештә транспорт оешмаларына Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 12 ноябрендәге 672 номерлы карарына ((2022 елның 10 гыйнварындагы 7 номерлы карар нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертергә:

1.1. Гражданнарга ташламалы транспорт картасы буенча транспорт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле рәвештә транспорт оешмаларына Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 4 нче бүлегенә түбәндәге эчтәлекле пункт өстәргә:

«4.1.1. Бюджет акчаларын баш бүлүче, субсидия бирүче буларак, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты субсидияләр алучыларга карата алар тарафыннан субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары үтәлешен мәҗбүри тикшерүне, шул исәптән аларны бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә муниципаль финанс тикшерүе органнары тарафыннан тикшерүләр үткәрүне гамәлгә ашыра».

2. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (htt://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының рәсми сайтында (http://zainsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Г.Х.Никифорова
8(85558)30719